ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 163 15 март 2017 ел.

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маендагы 804 номерлы карары белән расланган ана (гаилә) капиталын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган индивидуаль торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләр башкаруны раслаучы документ бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 1491 номерлы карары нигезендә, карар бирәм:

1.Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маендагы 804 номерлы карары белән расланган ана (гаилә) капиталын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган индивидуаль торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләр башкаруны раслаучы документ бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган кушымта итеп бирелгән (63 нче кушымта) үзгәрешләрне расларга.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотуны үз өстемә алам.

А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 15 мартындагы
163 номерлы карары белән расланган
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маендагы 804 номерлы карары белән расланган ана (гаилә) капиталын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган индивидуаль торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләр башкаруны раслаучы документ бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр

1.1. 1.3.1 пунктының 2 абзацында «Актүбә ур., 6» сүзләрен «Мәктәп бульвары, 2а» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 1.3.1 пунктының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ял һәм туклану өчен тәнәфес вакыты: 12 сәгать 00 минуттан 13 сәгать 00 минутка кадәр».

1.3. 1.3.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 10 абзац белән тулыландырырга: «Документлар 1 нче катта, электрон чират талонында күрсәтелгән тәрәзәдә кабул ителә.».

1.4. 1.4 пунктының 5 абзацында «24.01.2009, № 1» сүзләрен «18.02.2014, № 5» сүзләренә алмаштырырга.

1.5. 1.4 пунктының 6 абзацында «22.12.2010, № 17» сүзләрен «24.02.2015, №7» сүзләренә алмаштырырга.

1.6. 1.4 пунктының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Идарә турында нигезләмә».

1.7. 1.4 пунктын түбәндәге абзац белән тулыландырырга: «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 18 августындагы 686 номерлы «ана (гаилә) капиталы акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган индивидуаль торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләр башкаруны раслый торган документ бирү кагыйдәләрен раслау турында» карары белән».

1.8. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.3. пунктындагы 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «индивидуаль торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләрне башкаруны тикшерү акты».

1.9. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.4. пунктындагы «сигез» сүзен «ун» сүзенә алмаштырырга.

1.10. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.6 пунктын түбәндәге эчтәлекле 3 һәм 4 пунктчалар белән тулыландырырга:

«3) Төгәлләнмәгән төзелеш объектының, корылманың, бинаның кадастр паспорты.

4) Төзелешкә (реконструкцияләүгә) рөхсәт.».

1.11. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.8. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Каралмаган».

1.12. «Стандартка  таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.9 пунктындагы 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау».

1.13 .«Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.9 пунктын түбәндәге эчтәлекле 4 һәм 5 пунктлар белән тулыландырырга:

«4) индивидуаль торак төзелеше объектын төзү буенча төп эшләр башкарылуын тикшерү барышында (фундаментны монтажлау, стеналарны һәм түбәне торгызу) мондый эшләрнең тулы күләмдә башкарылмавы ачыкланачак;

5) индивидуаль торак төзелеше объектын реконструкцияләү эшләрен тикшерү барышында мондый эшләр нәтиҗәсендә торак урынының гомуми мәйданы артмавы, яисә Россия Федерациясе торак законнары нигезендә билгеләнә торган торак урыны мәйданының исәпкә алу нормасыннан кимрәк артуы билгеләнәчәк.».

1.14. «Стандарт таләпләре эчтәлеге» баганасының 2.13. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза кергән көнне административ регламентның 3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә башкарыла.».

1.15. «Стандарт таләпләре исеме» баганасының 2.14. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрне көтү һәм кабул итү урынына, шул исәптән әлеге объектларның инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә үтемлелеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр».

1.16. «Стандарт таләпләре эчтәлеге» баганасының 2.14. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда  гамәлгә ашырыла.

Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алуы тәэмин ителә (бинага керү-чыгу һәм алар чикләрендә күчү уңайлы).

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.».

1.17. «Стандарт таләпләре эчтәлеге» баганасының 2.15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

урын җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге зонасында урнашкан;

кирәкле белгечләр саны, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләр булу;

муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмати такталарда, «Интернет» челтәрендә, Түбән Кама муниципаль райо-нының рәсми сайтында тулы мәгълүмат;

законда каралган инвалидлар өчен уңайлы шартлар булу.

Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләр булмавы белән характерлана:

гариза бирүчеләргә документлар кабул итү һәм бирү чиратлары;

муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;

муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр;

муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтләренә карата шикаятьләр.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ), КФҮнең читтән торып эш урыннарында муниципаль хезмәт күрсәткәндә, консультация, документларны кабул итү һәм бирүне КФҮ белгече башкара.»

1. 18. 3.3.1 пунктының 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.1. Мөрәҗәгать итүче планлаштырыла торган елның алдыннан килүче елның 1 гыйнварыннан алып 1 июленә кадәр шәхсән үзе аның исәп эше, планлаштырылган елда сертификат бирү турында язма гариза һәм әлеге регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар урнашкан җирле үзидарә органына тапшыра.».

1.19. 3.3.2 пунктының 5 һәм 9 абзацларын төшереп калдырырга.

1.20. 3.3.2 пунктының 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Идарә белгече гамәлгә ашыра:».

1.21. 3.5.2 пунктындагы «Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары тарафыннан» сүзләрен «Башкарма комитет җитәкчесе (аның вәкаләтле заты)» сүзләренә алмаштырырга.

1.22. 3.5.3. пунктындагы «Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан» сүзләрен «Башкарма комитет җитәкчесе (аның вәкаләтле заты)» сүзләренә алмаштырырга.

1.23. 4.2 пунктындагы «Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары, шулай ук инфраструктура үсеше бүлеге белгечләре» сүзләрен «Башкарма комитет җитәкчесе (аның вәкаләтле заты)» сүзләренә алмаштырырга.

1.24. 5.1. пунктында «яки муниципаль берәмлеге Советына» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.25. 5.7 пунктында «(муниципаль район башлыгы)» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.26. Административ регламентка 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

1 нче кушымта

Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы

